РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

« 13 » 07 2022 г. | № 554

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 11.05.2022 ел, № 352 карары белән расланган «Ютазы муниципаль районында 2012-2024 елларга спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белщн кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә һәм спортның культивацияләнә торган төрләрен үстерү өчен шартлар тәэмин итү, җыелма командаларны формалаштыру, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының конкурентлыкка сәләтле спорт абруен күтәрү һәм ныгыту максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 11.05.2022 ел, № 352 карары белән расланган " 2022-2024 елларга Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. "Программаны эшләү өчен нигезләр» бүлегендә «Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт турында» 1999 елның 1 декабрендәге 2476 номерлы Законын «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына алмаштырырга;

1.2. "Елларга бүленеп программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Елларга бүлеп Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>Программаны финанслау муниципаль, республика бюджетлары һәм җәлеп ителгән акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.
<table>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру еллары</td><td>1-нче ел/ мең сум</td><td>2-нче ел/ мең сум</td><td>3-нче ел/ мең сум</td><td>Барлыгы мең сум</td></tr>
<tr><td>Барлык Чыганаклар буенча</td><td>37 336,15</td><td>36 986,7</td><td>37 245,8</td><td>111 568,55</td></tr>
<tr><td>Ютазы муниципаль районы бюджеты чараларыннан</td><td>33 546,71</td><td>33 791,0</td><td>34 050,1</td><td>101 387,81</td></tr>
<tr><td>Спорт чаралары:</td><td>2 189,44</td><td>1 595,7</td><td>1 595,7</td><td>5 380,84</td></tr>
<tr><td>Из средств бюдже-та Татарстан Республикасы бюджеты чараларыннан, шулардан:</td><td>593,74</td><td>0</td><td>0</td><td>593,74</td></tr>
<tr><td>- Спорт мәктәпләрен тәэмин итү өчен спорт җайланмаларын, экипировкалар һәм инвентарь сатып алу</td><td>117,7</td><td>0</td><td>0</td><td>117,7</td></tr>
<tr><td>Өстәмә җәлеп ителгән чаралар</td><td>1 600,0</td><td>1 600,0</td><td>1 600,0</td><td>4 800,0</td></tr>
</table>
Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл һәм шәһәр җирлекләре бюджетлары проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>
Җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчалары ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.</td>
</tr>
</table>

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 11.05.2022 ел, №352 карары белән расланган «2022-2024 елларга Ютазы муниципаль

районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында»26.05.2022 ел, №399 карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С. П. Самонина

Башк. Галләмова Р. А.
тел. (85593) 2-81-97